# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

27 ноябрь, 2024 ел №2

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Югары Шәмәрдән авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Югары Шәмәрдән авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Ядегәр авыл җирлегенең Югары Шәмәрдән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз әниләр, 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Югары Шәмәрдән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Югары Шәмәрдән авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү һәм килешү буенча түләү);

2) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су күтәрү манараларын тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су күтәрү манараларын тоту буенча башка эш төрләре);

3) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү (Югары Шәмәрдән авылындагы чишмәләрне ремонтлау, тоту, төзекләндерү, коймалы баскычлар урнаштыру, проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру, чишмәләрне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре);

4) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Югары Шәмәрдән авылындагы юлларны кышкы-җәйге тоту һәм проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү), (устройство, ремонт и благоустройство дорог с щебеночным покрытием по ул.Октябрьская, ул.Майская, ул.Х.Ямашева, ул.Восточная д.Верхний Шемордан, проектно-сметная документация и осуществление технадзора, прочие виды работ по устройству, содержанию и благоустройству дорог);

(Май урамы, Октябрь урамы, Көнчыгыш урамы, Х. Ямашев урамы, Югары Шәмәрдән авылы таш белән капланган юлларны чокырлы ремонтлау һәм проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү);

5) торак пункт территориясен төзекләндерү (Югары Шәмәрдән авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

(халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны Ядегәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ядегәр авыл җирлеге
башлыгы: А.Н.Фәйзуллин